**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

____22.11.2022____ г.Казань №_________538____________

**Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ маддәсендәге 1 пунктның икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февраленнән «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февраленнән «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләргә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 178 номерлы карары нигезендә

**б о е р а м:**

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен расларга.
2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары Х.Х Шәйхетдиновка, министр урынбасары И.Х. Садриевка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
_22.11.2022__________
нан 538 номерлы
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – гамәлгә куючы) тарафыннан гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә (алга таба – учреждение) дәүләт программалары чараларын тормышка ашыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели (алга таба – Тәртип).

2. Субсидияләр Учреждениегә түбәндәге максатларга бирелә:

түбәндәге дәүләт программаларының подпрограммаларын тормышка ашыру кысаларында чаралар үткәрүгә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартыннан 159 номерлы карары белән расланган «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы:

«2019-2025 елларга физик культура һәм массакүләм спортны үстерү» подпрограммасы;

«2019-2025 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү» подпрограммасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартыннан 158 номерлы карары белән расланган «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы:

«2019-2025 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру» подпрограммасы;

«2019-2025 елларга Татарстан яшьләре» подпрограммасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 февраленнән 110 номерлы карары белән расланган «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы:

«2014-2025 елларга өстәмә белем бирүне, шул исәптән инвалид балаларга, үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» подпрограммасы;

«2014-2025 елларга һөнәри һәм вуздан соңгы белем бирүне үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» подпрограммасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 декабреннән 1023 номерлы карары белән расланган «2014-2025 елларга

Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы:

2014-2025 арга «Социаль түләүләр» подпрограммасы;

4. Субсидия – учреждениегә тиешле финанс елына һәм планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет чаралары һәм гамәлгә куючыга билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә чараларны баш бүлүче һәм алучы функцияләрен һәм вәкаләтләрен тормышка ашыручы гамәлгә куючы тарафыннан куела торган чараларны тормышка ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бирелә торган субсидия ул.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

4. Гамәлгә куючы Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче булып тора, аңа кадәр, бюджет акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә тиешле финанс елына учреждениегә субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелде.

## II. Субсидияне бирү шартлары һәм тәртибе

5. Субсидия алу максатларында учреждение гамәлгә куючы адресына түбәндәгеләрне үз эченә алган документларның тулы исемлеген тапшыра:

учреждение җитәкчесенең ирекле рәвештә рәсмиләштерелгән субсидия алу өчен язма мөрәҗәгатен;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга бюджет чаралары бирү кирәклеген нигезләгән, субсидияләр суммасын нигезле исәпләүне дә кертеп, шул исәптән подпрограммада каралган чараларны гамәлгә ашыруга беренчел смета белән, аларның күләмен нигезли торган мәгълүмат (товарлар һәм хезмәт күрсәтүчеләрнең счетлары, коммерция тәкъдимнәре, җитештерүчеләрнең бәяләре, дәүләт статистикасы органнарының бәяләре турында мәгълүмат, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбият чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын да кертеп, һәм (яисә) башка мәгълүмат) нигезендә чыгымнарның планлаштырыла торган юнәлешләре калькуляциясен үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләүле аңлатма язуын;

учреждениенең субсидияләр бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айга кадәр килгән айның беренче числосына, учреждениене үзгәртеп кору яисә юкка чыгару, авария (гадәттән тыш) хәлләрен юкка чыгару, авария (гадәттән тыш хәл) килеп туган очракта аның нәтиҗәләрен юкка чыгару һәм торгызу эшләрен башкару буенча чараларны тормышка ашыруга, шулай ук законлы көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча бурычны каплауга субсидияләр бирү очракларыннан, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте актларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының муниципаль хокукый актларында, җирле администрациянең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, шул исәптән башка

хокукый актлар нигезендә билгеләнгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча вакыты чыккан бурычы булмау турында учреждение җитәкчесе һәм баш хисапчы яисә башка вәкаләтле вәкилнең имзасы белән расланган белешмәне;

субсидияләр бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айдан алдагы айның беренче числосына салым түләүче тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеня, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларны үтәү турында салым органы белешмәсен.

Тапшырыла торган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, моңа учреждение мөһере белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән рәсмиләштерелгән яисә учреждение җитәкчесенең үз кулы белән рәсмиләштерелгән төзәтмәләр керми. Документларның күчермәләре учреждение мөһере (булган очракта) белән расланырга һәм шуңа вәкаләтле затның имзасы белән яисә учреждение җитәкчесенең үз кулы белән расланырга тиеш. Учреждение җитәкчесенең язма мөрәҗәгате учреждениенең мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм шуңа вәкаләтле затның имзасы белән яисә учреждение җитәкчесенең үз кулы белән расланырга тиеш.

Учреждение үзе тәкъдим иткән документларны сорап алырга һәм документларны әлеге Тәртипнең әлеге пункты нигезендә кабат тапшырырга хокуклы.

6. Субсидия алу өчен документлар Гамәлгә куючы тарафыннан кергән көнне журналда теркәлә, ул номерланган, тегелгән һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеген алган көннән алып 15 эш көне эчендә аларны карый, аларда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм учреждениегә субсидия бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында хәбәр итә.

7. Учреждениегә субсидияләр бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

8. Субсидия Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә.

Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + З_4 + З_5 + З_6 + З_7 + З_8 + З_9 + З_{10} + З_{11} + З_{12} + З_{13} + З_{14},$$

монда:

$З_1$ – хезмәт законнары нигезендә учреждение хезмәткәрләренә, шулай ук подпрограмма чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган җәлеп ителгән белгечләргә хезмәт хакы түләү буенча чыгымнар;

$З_2$ – учреждениенең подпрограмма чарасын гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләренең командировкаларына киткән чыгымнары;

$З_3$ – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамәләр кысаларында учреждение милкен тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү эшләрен оештыруга һәм уздыруга, коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча чыгымнар;

$З_4$ – һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыру буенча чыгымнар;

$З_5$ – һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларга стипендияләр түләү буенча чыгымнар;

$З_6$ – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамәләр кысаларында уку курсларын һәм тренингларны оештыруга һәм уздыруга, тармакның аттестация уза торган хезмәткәрләренә экспертиза ясауга, рәсми спорт чараларында катнашучыларны аккредитацияләү буенча чыгымнар;

$З_7$ – алар тиңдәш (бертөрле) товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән җитештерүче-оештыручыларның бәяләре турындагы мәгълүматны анализлауда, дәүләт статистика органнарында булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларындагы, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм товар китерүчеләрнең рәсми сайтларын да кертеп, мәгълүматны анализлауга нигезләнгән төп чаралар һәм матди запасларның (спорт җиһазларын һәм инвентарен сатып алу, экипировка, медицина, медицина-савыктыру җиһазларын, шул исәптән ветеринария препаратларын, бүләкләү атрибутикасын, укыту-методик, чыгым материалын, оештыру техникасын сатып алу) бәясен арттыру буенча чыгымнар;

$З_8$ – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамәләр кысаларында азык-төлек продуктларын һәм сөт продукциясен сатып алу буенча чыгымнар;

$З_9$ – рәсми спорт чараларын уздыру кысаларында спортчыларның, спорт судьялары һәм башка катнашучыларның командировка чыгымнарын, шул исәптән старт һәм оештыру җыеннары, спорт объектлары хезмәтләре өчен түләү буенча чыгымнар

$З_{10}$ – рәсми спорт чараларында хезмәт күрсәткән өчен спорт судьялары, административ-хуҗалык һәм хезмәт күрсәтүче персонал эшенә түләү буенча чыгымнар;

$З_{11}$ – мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү, рәсми спорт чараларын уздыру урыннарын әзерләү, спорт объектларында иминлекне тәэмин итүгә түләү буенча чыгымнар;

$З_{12}$ – транспорт белән тәэмин итүгә, шул исәптән ягулык-майлау материалларына чыгымнар;

$З_{13}$ – ведомство буйсынуындагы учреждениеләр базасында профильле сменалар оештыруга һәм уздыруга чыгымнар;

$З_{14}$ – учреждение эшчәнлегенең максатлары һәм юнәлешләре белән билгеләнә торган башка чыгымнар.

9. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә куючы һәм учреждение тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2016 елның 22 декабреннән «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ маддәсендәге 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә субсидияләр бирү

турында килешүнең тип формасын раслау турында» 17-148 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча түбәндәге нигезләмәләрне үз өченә алган субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзелә:

подпрограмма атамасын күрсәтеп, субсидия бирү максатлары;

анык, үлчәнергә һәм подпрограмма нәтиҗәләренә туры килергә тиешле субсидия бирү нәтиҗәләренең билгеләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралары планы;

субсидия күләме;

субсидияне күчерү вакыты (графигы);

хисап бирү вакыты һәм тәртибе;

учреждение тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгән очракта, субсидия күләмен кире кайтару тәртибе һәм вакыты;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән гамәлгә куючыга субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта;

гамәлгә куючы карары буенча килешүне вакытыннан алда туктату өчен бер яклы тәртиптә, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә, нигезләр:

учреждениене үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яисә юкка чыгару;

учреждениенең хокукый акт һәм (яисә) килешү нигезендә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозуы;

учреждение тарафыннан килешүне бер яклы тәртиптә өзүне тыю.

Кирәк булган очракта, гамәлгә куючы һәм учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типовой формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү яисә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

10. Субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айдан алдагы айның беренче числосына учреждение туры килергә тиешле таләпләр:

учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеня, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарлымаган бурычлары, Татарстан Республикасы бюджетына шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы булмау, (моңа реорганизацияләү (кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш) яисә учреждениене юкка чыгару, авария (гадәттән тыш) хәлләрне булдырмау, гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта зыянны юкка чыгару һәм торгызу эшләрен башкару, үз көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары, җирле администрациянең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка барлыкка килгән бурычларны каплау очраклары керми).

11. Субсидия бирү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

уздырылган спорт, тамаша кылу, гавәми һәм башка массакүләм чаралар санын тәэмин итү (бердән дә ким түгел).

субсидия мөлкәт сатып алуга бирелгән очракта, сатып алынган мөлкәт объектлары саны (бердән дә ким түгел).

12. Гамәлгә куючы субсидияләрне килешү белән каралган субсидияне күчерү графигы нигезендә учреждениенең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап счетларына тулы күләмдә күчерә.

## III. Хисап бирүгә таләпләр

13. Учреждение гамәлгә куючыга квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә беркетелгән форма буенча финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чынлыкта башкарылган чыгымнарны раслый торган расланган документлар кушымтасы белән чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә беркетелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап.

## IV. Субсидия бирү максатларын, шартлары һәм тәртибен үтәүне тикшерүне башкару тәртибе һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

14. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс тикшерүен тормышка ашыручы вәкаләтле орган мәҗбүри тәртиптә учреждениегә субсидияләр бирү максатлары һәм шартларының үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

15. Учреждение субсидия алу өчен яисә субсидияне куллану турында дөрес булмаган белешмә һәм документлар тапшырган, Тәртип нигезендә субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шулай ук субсидияне тоту максатларын бозган, шулай ук әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән хисаплылыкны бирмәү өчен җаваплы.

Учреждениене җаваплылык чараларын кулланудан азат итү өчен нигез булып учреждениенең йөкләмәләрен үтәүгә комачаулый торган җиңеп булмый торган көчләр барлыкка килүнең документаль расланган булуы тора.

16. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс тикшерүен тормышка ашыручы вәкаләтле орган тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган субсидия биргәндә билгеләнгән максатлар, шартлар һәм тәртипләр үтәлмәгән очракта, субсидия учреждение тарафыннан гамәлгә куючының тиешле таләбе алынган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек вакыт аралыгында Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешмәгән очракта, субсидия гамәлгә куючының тиешле таләбе алынган көннән алып эш көннәрендә хисаплана торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

17. Агымдагы финанс елында файдаланылмаган әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешүгә бүлеп бирелгән субсидиянең чаралар калдыгы Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Гамәлгә куючы бүлеп бирелгән субсидиянең агымдагы финанс елында файдаланылмаган чаралар калдыгын әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә максатларга ирешүгә җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карарны агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата финанс белән тәэмин итү чыганагы буларак файдаланылмаган субсидияләр калдыклары буенча башкарылмаган йөкләмәләр барлыгы турында, шулай ук учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре булуын һәм күләмен (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) раслаучы документлар (документларның күчермәләре), субсидия бирелгән елдан соң килгән елның беренче 20 эш көне дәвамында учреждение тарафыннан юлланган мөрәҗәгать (алга таба – субсидияләр калдыклары буенча учреждение мөрәҗәгате) нигезендә кабул итә.

Гамәлгә куючы агымдагы финанс елында файдаланылмаган әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешүгә субсидия чаралар калдыгын юллауга ихтыяҗ булу турында карарны учреждениенең субсидияләр калдыклары буенча мөрәҗәгатен алган вакыттан алып биш эш көне эчендә кабул итә.

18. Әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә гамәлгә куючының агымдагы финанс елында файдаланылмаган максатларга ирешүгә субсидияләр калдыкларын җибәрүгә ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга юнәлдерелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен агымдагы финанс елында файдаланылырга мөмкин.

19. Агымдагы финанс елында, әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торган субсидияләр хисабына учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән кертемнәр булган очракта, учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре булуын һәм күләмен (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) раслаучы документлар (документларның күчермәләре) һәм субсидия бирелгән елдан соң килгән елның беренче 20 эш көне дәвамында учреждение тарафыннан юлланган финанс белән тәэмин итү чыганагы буларак файдаланылмаган субсидияләр калдыклары буенча башкарылмаган йөкләмәләр барлыгы турында мөрәҗәгать (алга таба – учреждениенең элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан килгән чаралар буенча мөрәҗәгате) нигезендә гамәлгә куючы учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен учреждение тарафыннан аларны файдалану турында карар кабул итә.

Гамәлгә куючы агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән кертемнәрнеагымдагы финанс елында файдалану турында карарны әлеге учреждениенең элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан килгән чаралар буенча мөрәҗәгать иткән вакыттан алып биш эш көне эчендә кабул итә.

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә
куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен
башкара торган Татарстан Республикасы
дәүләт бюджет һәм автоном
учреждениеләргә Татарстан Республикасы
бюджетыннан башка максатларга
субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын
билгеләү тәртибенә
1нче кушымта

Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны башкару турында хисаплылык

Учреждение атамасы: ____________________________________________
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче унарлы билгегә кадәр төгәллек белән)

| Чыгымнар юнәлеше | Сумма | |
|---|---|---|
| | хисап чоры өчен | ел башыннан үсә барган нәтиҗә белән |
| 1 | 2 | 3 |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия чаралары килү | | |
| Кулланылган субсидия чаралары (касса чыгымы) | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылган | | |
| Хисап чоры азагына субсидия калдыгы | | |
| шул исәптән: кире кайтарылырга тиешле | | |

Гамәлгә куючы

_______________________/ФИАи/
М.У.

Учреждение

___________________________/ФИАи/
М.У. (булган очракта)

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
2нче кушымта

Субсидия бирү нәтиҗәсенә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәк булган күрсәткечкә ирешү буенча хисаплылык

Учреждение атамасы: ______________________________________________

| N | Күрсәткеч атамасы | ____ елга план күрсәткече | Күрсәткечнең хисап көненә карата ирешелгән күрсәткече | Планны үтәү проценты | Тайпылыш сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Гамәлгә куючы

________________________/ФИАи/
М.У.

Учреждение

___________________________/ФИАи/
М.У. (булган очракта)